| | |
|---|---|
| ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БОРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 11.04.2018 | 1 |

с. Татарское Бурнашево

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге «Каинка» коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау» проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең уңай яшәү шартларына, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, 29.12.2004 ел, № 190-ФЗ РФ Шәһәр төзелеше кодексының 24.08 ст. нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131–ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставына таянып.

Карар бирәм

1.2018 елның 14 маенда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге «Каинка» коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау» проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2.Бурнаш авыл җирлеге башкарма комитеты бинасын гавами тыңлаулар үткәрү урыны итеп: Татар Борнашы авылы, Совет урамы, 62 нче йорт адресы буенча билгеләргә. Үткәрү көне - 2018 елның 14 мае, үткәрү вакыты - 15.00.
Фикер алышучы мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татар Борнашы ав., Совет ур., 62 й.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарны Югары Ослан районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин